КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 16 ноябрь г.Казань № 1001

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә коррупциягә каршы чараларны тормышка ашыру буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары, башка дәүләт органнары һәм оешмалар эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге мониторингын оештыру һәм үткәрү турында» 2011 ел, 10 июнь, 463 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә коррупциягә каршы чараларны тормышка ашыру буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары, башка дәүләт органнары һәм оешмалар эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге мониторингын оештыру һәм үткәрү турында» 2011 ел, 10 июнь, 463 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 30 август, 625 нче; 2015 ел, 11 ноябрь, 844 нче; 2016 ел, 9 июнь, 375 нче; 2017 ел, 20 апрель, 232 нче

карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы территориясендә коррупциягә каршы чараларны тормышка ашыру буенча, шулай ук мониторинг үткәрергә вәкаләтле органның башка дәүләт органнары белән коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча мәгълүмати хезмәттәшлеген тәэмин итү буенча эшчәнлеге нәтиҗәлелегенә мониторинг оештыру һәм үткәрү чаралары турында»;

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге ФЗ-273 номерлы Федераль законны, «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору турында» 2006 елның 4 маендагы ТРЗ-34 номерлы Татарстан Республикасы Законын, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы территориясендә коррупциягә каршы чараларны гамәлгә ашыру буенча, шулай ук мониторинг үткәрергә вәкаләтле органның башка дәүләт органнары белән коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча мәгълүмати хезмәттәшлеген тәэмин итү буенча эшчәнлеге нәтиҗәлелегенә мониторинг оештыру һәм үткәрү чаралары турында» 2011 елның 23 мартындагы ПУ-148 номерлы Указын тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы территориясендә коррупциягә каршы чараларны тормышка ашыру буенча, шулай ук мониторинг үткәрергә вәкаләтле органның башка дәүләт органнары белән коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча мәгълүмати хезмәттәшлеген тәэмин итү буенча эшчәнлеге нәтиҗәлелегенә мониторинг гамәлгә ашыру өчен мәгълүмат урнаштыру (бирү) регламентын (алга таба – Регламент) расларга.»;

2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарына, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары булмаган башка Татарстан Республикасы дәүләт органнарына, Татарстан Республикасы прокуратурасына, Суд департаментының Татарстан Республикасындагы идарәсенә Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты белән коррупциягә

каршы тору мәсьәләләре буенча мәгълүмати хезмәттәшлек турында килешүләр төзүне тәкъдим итәргә.»;

3 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетына түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы территориясендә коррупциягә каршы чараларны тормышка ашыру буенча эшчәнлеге нәтиҗәлелегенә мониторинг (алга таба – мониторинг) оештыруны һәм үткәрүне;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары булмаган башка дәүләт органнары (алга таба – башка дәүләт органнары), Татарстан Республикасы прокуратурасы, Суд департаментының Татарстан Республикасындагы идарәсе белән коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча мәгълүмати хезмәттәшлекне;

Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары тарафыннан «Ачык Татарстан» мәгълүмат порталының «Ведомстволар хисаплары» бердәм дәүләт хисап системасында (алга таба – Система) мониторингны гамәлгә ашыру өчен түбәндәгеләр нигезендә үз вакытында мәгълүмат урнаштыруны тикшерүдә тотуны:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы территориясендә коррупциягә каршы чараларны гамәлгә ашыру буенча, шулай ук мониторинг үткәрергә вәкаләтле органның башка дәүләт органнары белән коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча мәгълүмати хезмәттәшлеген тәэмин итү буенча эшчәнлеге нәтиҗәлелегенә мониторинг оештыру һәм үткәрү чаралары турында» 2011 елның 23 мартындагы ПУ-148 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы территориясендә коррупциягә каршы чараларны тормышка ашыру буенча, шулай ук мониторинг үткәрергә вәкаләтле органның башка дәүләт органнары белән коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча мәгълүмати хезмәттәшлеген тәэмин итү буенча эшчәнлеге нәтиҗәлелегенә мониторинг үткәрү өчен төп күрсәткечләр исемлеге (алга таба – Мониторинг үткәрү өчен төп күрсәткечләр исемлеге);

бу карар белән расланган Регламентка теркәлгән 1 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр

округлары җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы территориясендә коррупциягә каршы чараларны тормышка ашыру буенча эшчәнлеге нәтиҗәлелегенә мониторинг үткәрү өчен өстәмә күрсәткечләр исемлеге (алга таба – Мониторинг үткәрү өчен өстәмә күрсәткечләр исемлеге);

башка дәүләт органнары, Татарстан Республикасы прокуратурасы, Суд департаментының Татарстан Республикасындагы идарәсе тарафыннан – бу карар белән расланган Регламентка теркәлгән 2 нче кушымта нигезендә Башка дәүләт органнары белән коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча мәгълүмати хезмәттәшлек турындагы килешүләр нигезендә бирү гамәлгә ашырыла торган һәм мониторинг үткәрү өчен кирәкле булган коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча мәгълүмат исемлеге (алга таба – Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча мәгълүмат исемлеге) нигезендә;

мониторинг нәтиҗәләрен, шулай ук башка дәүләт органнарында, Татарстан Республикасы прокуратурасында, Суд департаментының Татарстан Республикасындагы идарәсендә коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча мәгълүматны (алга таба – коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча мәгълүмат) анализлау һәм гомумиләштерүне;

Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы территориясендә коррупциягә каршы чараларны тормышка ашыру буенча эшчәнлегенә мониторинг нәтиҗәләре, аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләре һәм критерийлары җыелмасы тасвирламасын үз эченә алган мониторинг нәтиҗәләре турында хисап (алга таба – мониторинг нәтиҗәләре турында хисап) һәм коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча мәгълүмат әзерләүне;

мониторинг нәтиҗәләре турындагы хисапны, шулай ук коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча мәгълүматны Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсенә һәм Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору эшен яраштыру комиссиясенә Комиссия утырышында карап тикшерү һәм Татарстан Республикасы территориясендә коррупциягә каршы тору өлкәсендә үз вәкаләтләре чикләрендә чаралар эшләү өчен җибәрү.»;

4 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарына мәгълүматны Системада Мониторинг үткәрү өчен төп күрсәткечләр исемлеге һәм Мониторинг үткәрү өчен өстәмә күрсәткечләр исемлеге нигезендә урнаштырырга.»;

түбәндәге эчтәлекле $4^{1}$ нче пункт өстәргә:

«41. «Татарстан Республикасының Мәгълүмат технологияләре үзәге» дәүләт унитар предприятиесенә Системада коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча мәгълүматка һәм мониторингка техник ярдәм күрсәтергә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә коррупциягә каршы чараларны тормышка ашыру буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары,

башка дәүләт органнары һәм оешмалар эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге мониторингын гамәлгә ашыру өчен мәгълүмат бирү регламентын (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2011 ел, 16 июнь, 463 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 16 ноябрь, 1001 нче
карары белән расланды)

Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының,
федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы территориясендә коррупциягә каршы чараларны тормышка ашыру буенча,
шулай ук мониторинг үткәрергә вәкаләтле органның башка дәүләт органнары белән коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча мәгълүмати хезмәттәшлеген
тәэмин итү буенча эшчәнлеге нәтиҗәлелегенә мониторинг гамәлгә ашыру өчен
мәгълүмат урнаштыру (бирү)
регламенты

1. Бу Регламент башкарма хакимият органнарының, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы территориясендә коррупциягә каршы чараларны тормышка ашыру буенча эшчәнлеге нәтиҗәлелегенә мониторинг гамәлгә ашыру өчен һәм мониторинг үткәрергә вәкаләтле органның Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары булмаган башка дәүләт органнары (алга таба – башка дәүләт органнары), Татарстан Республикасы прокуратурасы, Суд департаментының Татарстан Республикасындагы идарәсе белән коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча мәгълүмати хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру өчен мәгълүмат урнаштыру (бирү) тәртибен һәм эзлеклелеген билгели.

2. Мониторингны гамәлгә ашыру өчен мәгълүмат урнаштыручы (бирүче) мәгълүмати хезмәттәшлектә катнашучылар булып түбәндәгеләр тора:

Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары;

федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары;

Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары;

башка дәүләт органнары;

Татарстан Республикасы прокуратурасы;

Суд департаментының Татарстан Республикасындагы идарәсе.

Федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары, Татарстан Республикасы

прокуратурасы, Суд департаментының Татарстан Республикасындагы идарәсе мониторингны гамәлгә ашыру өчен «Ачык Татарстан» мәгълүмат порталының «Ведомстволар хисаплары» бердәм дәүләт хисап системасында (алга таба – Система) Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты белән коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча мәгълүмати хезмәттәшлек турында төзелгән килешүләр (алга таба – Килешү) нигезендә мәгълүмат урнаштыра.

3. Мониторинг һәм мониторингны гамәлгә ашыру өчен коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча мәгълүмати хезмәттәшлек түбәндәге этапларны үз эченә ала:

мәгълүмат җыю һәм аны эшкәртү;

мониторинг һәм коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча мәгълүмати хезмәттәшлек нәтиҗәләрен анализлау, бәяләү һәм хисап формалаштыру;

хисапны Системада, Татарстан Республикасы Социаль-икътисадый мониторинг комитетының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру, массакүләм мәгълүмат чаралары соравы буенча бирү.

4. Мониторингны гамәлгә ашыру өчен мәгълүматны Системада урнаштыру түбәндәге вакытларда гамәлгә ашырыла:

Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары тарафыннан:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы территориясендә коррупциягә каршы чараларны гамәлгә ашыру буенча, шулай ук мониторинг үткәрергә вәкаләтле органның башка дәүләт органнары белән коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча мәгълүмати хезмәттәшлеген тәэмин итү буенча эшчәнлеге нәтиҗәлелегенә мониторинг оештыру һәм үткәрү чаралары турында» 2011 елның 23 мартындагы ПУ-148 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы территориясендә коррупциягә каршы чараларны тормышка ашыру буенча, шулай ук мониторинг үткәрергә вәкаләтле органның башка дәүләт органнары белән коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча мәгълүмати хезмәттәшлеген тәэмин итү буенча эшчәнлеге нәтиҗәлелегенә мониторинг үткәрү өчен төп күрсәткечләр исемлеге (алга таба – Мониторинг үткәрү өчен төп күрсәткечләр исемлеге) буенча – хисап кварталыннан соң килүче айның 10 сына кадәр, ел йомгаклары буенча – хисап елыннан соң килүче айның 15 енә кадәр;

бу карар белән расланган Регламентка теркәлгән 1 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы территориясендә коррупциягә каршы чараларны тормышка ашыру буенча эшчәнлеге нәтиҗәлелегенә мониторинг үткәрү өчен өстәмә күрсәткечләр исемлеге (алга таба – Мониторинг

үткәрү өчен өстәмә күрсәткечләр исемлеге) буенча – хисап ярты еллыгыннан соң килүче айның 15 енә кадәр һәм хисап елыннан соң килүче айның 15 енә кадәр;

федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары тарафыннан:

Мониторинг үткәрү өчен төп күрсәткечләр исемлеге һәм Мониторинг үткәрү өчен өстәмә күрсәткечләр исемлеге буенча – хисап ярты елыннан соң килүче айның 15 енә кадәр һәм хисап елыннан соң килүче айның 15 енә кадәр;

Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары тарафыннан:

Мониторинг үткәрү өчен төп күрсәткечләр исемлеге буенча – хисап кварталыннан соң килүче айның 10 сына кадәр, ел йомгаклары буенча – хисап елыннан соң килүче айның 15 енә кадәр;

Мониторинг үткәрү өчен өстәмә күрсәткечләр исемлеге буенча – хисап ярты еллыгыннан соң килүче айның 15 енә кадәр һәм хисап елыннан соң килүче айның 15 енә кадәр;

башка дәүләт органнары тарафыннан:

Мониторинг үткәрү өчен төп күрсәткечләр исемлеге буенча – хисап кварталыннан соң килүче айның 10 сына кадәр, ел йомгаклары буенча – хисап елыннан соң килүче айның 15 енә кадәр;

Татарстан Республикасы прокуратурасы, Суд департаментының Татарстан Республикасындагы идарәсе, Татарстан Республикасының Хисап палатасы, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы тарафыннан бу карар белән расланган Регламентка теркәлгән 2 нче кушымта нигезендә Башка дәүләт органнары белән коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча мәгълүмати хезмәттәшлек турындагы килешүләр нигезендә бирү гамәлгә ашырыла торган һәм мониторинг үткәрү өчен кирәкле булган коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча мәгълүмат исемлеге (алга таба – Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча мәгълүмат исемлеге) буенча – хисап ярты елыннан соң килүче айның 15 енә кадәр һәм хисап елыннан соң килүче айның 15 енә кадәр;

Суд департаментының Татарстан Республикасындагы идарәсе мәгълүматларны хисап ярты еллыгыннан соң килүче икенче айның 15 енә кадәр һәм хисап елыннан соң килүче икенче айның 15 енә кадәр бирә.

Мониторингны гамәлгә ашыру өчен Мониторинг үткәрү өчен төп күрсәткечләр исемлеге, Мониторинг үткәрү өчен өстәмә күрсәткечләр исемлеге, Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча мәгълүмат исемлеге нигезендә Системада мәгълүмат урнаштырырга техник мөмкинлеге булмаган федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары, Татарстан Республикасы прокуратурасы, Суд департаментының Татарстан Республикасындагы идарәсе мониторингны гамәлгә ашыру өчен мәгълүматны Татарстан Республикасы социаль-икътисадый мониторинг комитетына бу пункт белән билгеләнгән вакытларда, Килешүдә күрсәтелгән форма буенча кертә.

5. Системада Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының

җирле үзидарә органнары, башка дәүләт органнары тарафыннан Мониторинг үткәрү өчен төп күрсәткечләр исемлеге буенча мониторингны гамәлгә ашыру өчен мәгълүмат урнаштыру Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе тарафыннан координацияләгәндә гамәлгә ашырыла.

6. Мәгълүматларны туплау һәм системалаштыру максатларында, Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетында Мониторинг үткәрү өчен төп күрсәткечләр исемлеге, Мониторинг үткәрү өчен өстәмә күрсәткечләр исемлеге, Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча мәгълүмат исемлеге белән күздә тотылган мәгълүматлар күләмендә мәгълүмат банкы төзелә.

7. Системада урнаштырыла торган яки мәгълүмати хезмәттәшлектә катнашучылар тарафыннан башка формада бирелә торган мониторинг үткәрү өчен мәгълүматның тулылыгы, актуальлеге һәм дөреслеге өчен Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары, башка дәүләт органнары, Татарстан Республикасы прокуратурасы, Суд департаментының Татарстан Республикасындагы идарәсенең мәгълүмат урнаштырган яки биргән җитәкчеләре җавап бирә.

Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы территориясендә коррупциягә каршы чараларны тормышка ашыру буенча, шулай ук мониторинг үткәрергә вәкаләтле органның башка дәүләт органнары белән коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча мәгълүмати хезмәттәшлеген тәэмин итү буенча эшчәнлеге нәтиҗәлелегенә мониторинг гамәлгә ашыру өчен мәгълүмат урнаштыру (бирү) регламентына
1 нче кушымта

Форма

**Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы территориясендә коррупциягә каршы чараларны тормышка ашыру буенча эшчәнлеге нәтиҗәлелегенә мониторинг үткәрү өчен өстәмә күрсәткечләр исемлеге**

| Күрсәткеч исеме | Мониторингны гамәлгә ашыру өчен мәгълүмат урнаштыручы (бирүче) мәгълүмати хезмәттәшлектә катнашучылар |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 1. Дәүләт граждан хезмәткәрләре, шул исәптән дәүләт хезмәте вазыйфасына яңа билгеләнгән хезмәткәрләр белән аларның чикләүләрен һәм тыюларын, дәүләт граждан хезмәте турындагы законнар нигезендә мәнфәгатьләр низагларын булдырмау яки җайга салу таләпләрен, шулай ук «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль закон белән билгеләнгән таләпләрне үтәү турында профилактик әңгәмәләр үткәрү саны/<br>2. Дәүләт хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә үткәрелгән конкурслар (шул исәптән кадрлар резервына кертүгә конкурслар) саны, шулардан | Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары (мәгълүмат Килешү нигезендә бирелә) |

| | |
|---|---|
| нәтиҗәләренә шикаять бирелгән була.<br>3. Хисап чоры өчен гражданнарның һәм оешмаларның дәүләт органына кергән түбәндәге өлкәләрдәге коррупцион хокук бозулар турындагы мөрәҗәгатьләре:<br>3.1. сәламәтлек саклау;<br>3.2. мәгариф;<br>3.3. торак-коммуналь хуҗалык һәм төзелеш;<br>4.4. агросәнәгать комплексы;<br>3.5. күчемсез мөлкәт белән эш итү;<br>3.6. хәрби хезмәткә чакыру кампаниясе;<br>3.7. башка өлкәдә.<br>4. Коррупциягә каршы тору буенча дәүләт органы җитәкчесе каршындагы комиссия утырышлары саны.<br>5. Дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан кылынган юридик һәм (яки) физик затларга дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын бозуга прецедентлар (нигезле шикаятьләр) булу (әйе/юк).<br>6. Прокуратура, юстиция органнары тарафыннан коррупциоген факторлар булу-булмауга коррупциягә каршы экспертиза үткән норматив хокукый актлар проектлары саны.<br>7. Прокуратура, юстиция органнары тарафыннан коррупциоген факторлар ачыкланган норматив хокукый актлар проектлары саны.<br>8. Дәүләт органы тарафыннан эшләнгән (расланган) һәм аларда прокуратура, юстиция органнары тарафыннан коррупциоген факторлар ачыклаган норматив хокукый актлар саны.<br>9. Бюджет акчасын файдалану өлкәсендә контроль буенча үткәрелгән чаралар нәтиҗәләре буенча ачыкланган хокук бозулар саны.<br>9.1. Бюджет акчасын файдалану өлкәсендә контроль буенча үткәрелгән чаралар нәтиҗәләре буенча ачыкланган хокук бозуларның суммада чагылышы, мең сум.<br>10. Дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр башкару, хезмәт күрсәтүләр буенча үткәрелгән сатып алулар саны.<br>11. Дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр башкару, хезмәт күрсәтүләр буенча билгеләнгән җитешсезлекләр белән үткәрелгән һәм гаеплеләрне түбәндәгеләргә җәлеп итү турында карар кабул ителгән сатып алулар саны: | |

| | |
|---|---|
| 11.1. дисциплинар җаваплылыкка;<br>11.2. административ җаваплылыкка;<br>11.3. җинаять җаваплылыгына.<br>12. Дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр башкару, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларда катнашу өчен бирелгән гаризалар саны – барлыгы,<br>12.1. шулардан сатып алуларда катнашуга рөхсәт ителмәгән.<br>13. Дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр башкару, хезмәт күрсәтүләрне сатып алуларга карата шикаять бирелгән процедуралар саны.<br>14. Дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр башкару, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар нәтиҗәләре буенча төзелгән килешүләрнең гомуми кыйммәте, мең сум.<br>14.1. Дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр башкару, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар нәтиҗәләре буенча төзелгән һәм бозулар булуы ачыкланган алыш-бирешләр кыйммәте, мең сум.<br>15. Дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр башкару, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турындагы законнар белән билгеләнгән таләпләрне үтәү, шулай ук лицензия-рөхсәт бирү эшчәнлеген (килештерү һәм теркәү процедураларын) гамәлгә ашыру буенча үткәрелгән тикшерүләр саны, шулардан:<br>15.1. үткәрелгән һәм гамәлдәге законнарны бозу очраклары ачыкланган тикшерүләр саны;<br>15.2. гамәлдәге законнарны бозу очраклары ачыкланган тикшерүләр нәтиҗәләре буенча хокук саклау органнарына җибәрелгән материаллар саны | |

| | |
|---|---|
| 1. Муниципаль хезмәткәрләр, шул исәптән муниципаль хезмәте вазыйфасына яңа билгеләнгән хезмәткәрләр белән аларның чикләүләрен һәм тыюларын, муниципаль хезмәт турындагы законнар нигезендә мәнфәгатьләр низагларын булдырмау яки җайга салу таләпләрен, шулай ук «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль закон белән билгеләнгән таләпләрне үтәү турында профилактик әңгәмәләр үткәрү саны.<br>2. Муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә үткәрелгән конкурслар (шул исәптән кадрлар резервына кертүгә конкурслар) саны, шулардан нәтиҗәләренә шикаять бирелгән була.<br>3. Хисап чоры өчен гражданнарның һәм оешмаларның җирле үзидарә органына кергән түбәндәге өлкәләрдәге коррупцион хокук бозулар турындагы мөрәҗәгатьләре саны:<br>3.1. сәламәтлек саклау;<br>3.2. мәгариф;<br>3.3. торак-коммуналь хуҗалык һәм төзелеш;<br>4.4. агросәнәгать комплексы;<br>3.5. күчемсез мөлкәт белән эш итү;<br>3.6. хәрби хезмәткә чакыру кампаниясе;<br>3.7. башка өлкәдә.<br>4. Коррупциягә каршы тору буенча җирле үзидарә органы җитәкчесе каршындагы комиссия утырышлары саны.<br>5. Муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан кылынган юридик һәм (яки) физик затларга дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын бозуга прецедентлар (нигезле шикаятьләр) булу (әйе/юк).<br>6. Мәктәп укучыларында һәм студентларда коррупциягә каршы караш формалаштыру максатларында, җирле үзидарә органында үткәрелә торган чаралар саны.<br>7. Прокуратура, юстиция органнары тарафыннан коррупциоген факторлар булу-булмауга коррупциягә каршы экспертиза үткән норматив хокукый актлар проектлары саны.<br>8. Прокуратура, юстиция органнары тарафыннан коррупциоген факторлар ачыкланган норматив хокукый актлар проектлары саны.<br>9. Дәүләт органы тарафыннан эшләнгән (расланган) һәм аларда прокуратура, юстиция органнары тарафыннан коррупциоген факторлар ачыклаган | Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары (алга таба – җирле үзидарә органы) (мәгълүмат Килешү нигезендә бирелә) |

| | |
|---|---|
| норматив хокукый актлар саны.<br>10. Бюджет акчасын файдалану өлкәсендә контроль буенча үткәрелгән чаралар нәтиҗәләре буенча ачыкланган хокук бозулар саны.<br>10.1. Бюджет акчасын файдалану өлкәсендә контроль буенча үткәрелгән чаралар нәтиҗәләре буенча ачыкланган хокук бозуларның суммада чагылышы, мең сум.<br>11. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр башкару, хезмәт күрсәтүләр буенча үткәрелгән сатып алулар саны.<br>12. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр башкару, хезмәт күрсәтүләр буенча билгеләнгән җитешсезлекләр белән үткәрелгән һәм гаеплеләрне түбәндәгеләргә җәлеп итү турында карар кабул ителгән сатып алулар саны:<br>12.1. дисциплинар җаваплылыкка;<br>12.2. административ җаваплылыкка;<br>12.3. җинаять җаваплылыгына.<br>13. Дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр башкару, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларда катнашу өчен бирелгән гаризалар саны – барлыгы,<br>13.1. шулардан сатып алуларда катнашуга рөхсәт ителмәгән.<br>14. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр башкару, хезмәт күрсәтүләрне сатып алуларга карата шикаять бирелгән процедуралар саны.<br>15. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр башкару, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар нәтиҗәләре буенча төзелгән килешүләрнең гомуми кыйммәте, мең сум.<br>15.1. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр башкару, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар нәтиҗәләре буенча төзелгән һәм бозулар булуы ачыкланган алыш-бирешләр кыйммәте, мең сум.<br>16. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр башкару, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турындагы законнар белән билгеләнгән таләпләрне үтәү, шулай ук лицензия-рөхсәт бирү эшчәнлеген (килештерү һәм теркәү процедураларын) гамәлгә ашыру буенча үткәрелгән тикшерүләр саны, шулардан: | |

| | |
|---|---|
| 16.1. үткәрелгән һәм гамәлдәге законнарны бозу очраклары ачыкланган тикшерүләр саны;<br>16.2. гамәлдәге законнарны бозу очраклары ачыкланган тикшерүләр нәтиҗәләре буенча хокук саклау органнарына җибәрелгән материаллар саны<br>17. Муниципаль милектәге мөлкәтне файдалану буенча үткәрелгән тикшерүләр саны, шулардан:<br>17.1. муниципаль милектәге мөлкәтне файдалануга карата гамәлдәге законнарны бозу очраклары ачыкланган тикшерүләр саны;<br>17.2. муниципаль милектәге мөлкәтне файдалануга карата гамәлдәге законнарны бозу очраклары ачыкланган тикшерүләр нәтиҗәләре буенча хокук саклау органнарына җибәрелгән материаллар саны | |

Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы территориясендә коррупциягә каршы чараларны тормышка ашыру буенча, шулай ук мониторинг үткәрергә вәкаләтле органның башка дәүләт органнары белән коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча мәгълүмати хезмәттәшлеген тәэмин итү буенча эшчәнлеге нәтиҗәлелегенә мониторинг гамәлгә ашыру өчен мәгълүмат урнаштыру (бирү) регламентына
2 нче кушымта

Форма

**Башка дәүләт органнары белән коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча мәгълүмати хезмәттәшлек турындагы килешүләр нигезендә бирү гамәлгә ашырыла торган һәм мониторинг үткәрү өчен кирәкле булган коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча мәгълүмат исемлеге**

| Күрсәткеч исеме | Мониторингны гамәлгә ашыру өчен мәгълүмат урнаштыручы (бирүче) мәгълүмати хезмәттәшлектә катнашучылар |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 1. Хисап чорында теркәлгән коррупциячел юнәлештәге җинаятьләр саны.<br>2. Алдан тикшерү стадиясендә туктатылган җинаять эшләре саны.<br>3. Судка җибәрелгән җинаять эшләре саны.<br>4. Коррупциячел юнәлештәге җинаятьләр буенча җинаять эшләре саны (аларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча суд тарафыннан гаепләү карарлары чыгарылган).<br>5. Коррупциячел юнәлештәге җинаятьләр кылган өчен хөкем ителгән затлар саны, шул исәптән:<br>5.1. республика закон чыгару хакимияте органнарында;<br>5.2. вәкиллекле хакимиятнең муниципаль органнарында;<br>5.3. республика башкарма хакимият орган- | Татарстан Республикасы прокуратурасы |

| | |
|---|---|
| нарында;<br>5.4. муниципаль башкарма хакимият органнарында;<br>5.5. Татарстан Республикасы территориясендә хокук саклау органнарында.<br>6. Гамәлдәге законнарның үтәлешенә күзәтчелекне гамәлгә ашырганда коррупциячел юнәлештәге ачыкланган бозулар саны, шул исәптән:<br>6.1. дәүләт (муниципаль) милкеннән файдалану турында;<br>6.2. бюджет турында;<br>6.3. дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында;<br>6.4. дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр башкару, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар турында;<br>6.5. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан җибәрелгән, шул исәптән түбәндәгеләргә бәйле рәвештә:<br>6.5.1. керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар тапшыруга;<br>6.5.2. мәнфәгатьләр низагларын җайга салмауга;<br>6.5.3. Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлары һәм кертемнәре булуга, чит ил финанс инструментларына ия булуга һәм (яки) алардан файдалануга;<br>6.5.4. коррупциячел хокук бозуларга һәвәсләнү турында хәбәрсез булуга;<br>6.5.5. эшмәкәрлек эшчәнлегендә, хуҗалык итүче субъект белән идарә итүдә катнашуга;<br>6.5.6. үзенә буйсынган зат белән якын туганнар булуга;<br>6.5.7. хезмәт вазыйфаларын башкаруга бәйле бүләкләр һәм башка түләүләр алуга;<br>6.5.8. хезмәт буенча башка чикләүләрне, тыюларны һәм йөкләмәләрне үтәмәүгә;<br>6.6. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче | |

| | |
|---|---|
| затлар тарафыннан җибәрелгән, шул исәптән түбәндәгеләргә бәйле рәвештә:<br>6.6.1. керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар тапшыруга;<br>6.6.2. мәнфәгатьләр низагларын җайга салмауга;<br>6.6.3. Россия Федерациясе территория-сеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлары һәм кертемнәре булуга, чит ил финанс инструментларына ия булуга һәм (яки) алардан файдалануга;<br>6.6.4. коррупциячел хокук бозуларга һәвәсләнү турында хәбәрсез булуга;<br>6.6.5. эшмәкәрлек эшчәнлегендә, хуҗалык итүче субъект белән идарә итүдә катнашуга;<br>6.6.6. үзенә буйсынган зат белән якын туганнар булуга;<br>6.6.7. хезмәт вазыйфаларын башкаруга бәйле бүләкләр һәм башка түләүләр алуга;<br>6.6.8. хезмәт буенча башка чикләүләрне, тыюларны һәм йөкләмәләрне үтәмәүгә;<br>6.7. Татарстан Республикасында муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан җибәрелгән, шул исәптән түбәндәгеләргә бәйле рәвештә:<br>6.7.1. керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар тапшыруга;<br>6.7.2. мәнфәгатьләр низагларын җайга салмауга;<br>6.7.3. Россия Федерациясе территория-сеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлары һәм кертемнәре булуга, чит ил финанс инструментларына ия булуга һәм (яки) алардан файдалануга;<br>6.7.4. коррупциячел хокук бозуларга һәвәсләнү турында хәбәрсез булуга; | |

| | |
|---|---|
| 6.7.5. эшмәкәрлек эшчәнлегендә, хуҗалык итүче субъект белән идарә итүдә катнашуга;<br>6.7.6. үзенә буйсынган зат белән якын туганнар булуга;<br>6.7.7. хезмәт вазыйфаларын башкаруга бәйле бүләкләр һәм башка түләүләр алуга;<br>6.7.8. хезмәт буенча башка чикләүләрне, тыюларны һәм йөкләмәләрне үтәмәүгә;<br>6.8. Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан җибәрелгән, шул исәптән:<br>6.8.1. керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар тапшыруга;<br>6.8.2. мәнфәгатьләр низагларын җайга салмауга;<br>6.8.3. Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлары һәм кертемнәре булуга, чит ил финанс инструментларына ия булуга һәм (яки) алардан файдалануга;<br>6.8.4. коррупциячел хокук бозуларга һәвәсләнү турында хәбәрсез булуга;<br>6.8.5. эшмәкәрлек эшчәнлегендә, хуҗалык итүче субъект белән идарә итүдә катнашуга;<br>6.8.6. үзенә буйсынган зат белән якын туганнар булуга;<br>6.8.7. хезмәт вазыйфаларын башкаруга бәйле бүләкләр һәм башка түләүләр алуга;<br>6.8.8. хезмәт буенча башка чикләүләрне, тыюларны һәм йөкләмәләрне үтәмәүгә;<br>7. Прокурор тәкъдиме буенча йөкләмәләрне үтәмәгән, тыюларны һәм чикләүләрне үтәмәгән өчен дисциплинар җаваплылыкка тартылды:<br>7.1. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар саны, шул исәптән түбәндәгеләргә бәйле рәвештә:<br>7.1.1. керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар тапшыруга;<br>7.1.2. мәнфәгатьләр низагларын җайга салмауга;<br>7.1.3. Россия Федерациясе территория- | |

| | |
|---|---|
| сеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлары һәм кертемнәре булуга, чит ил финанс инструментларына ия булуга һәм (яки) алардан файдалануга;<br>7.1.4. коррупциячел хокук бозуларга һәвәсләнү турында хәбәрсез булуга;<br>7.1.5. эшмәкәрлек эшчәнлегендә, хуҗалык итүче субъект белән идарә итүдә катнашуга;<br>7.1.6. үзенә буйсынган зат белән якын туганнар булуга;<br>7.1.7. хезмәт вазыйфаларын башкаруга бәйле бүләкләр һәм башка түләүләр алуга;<br>7.1.8. хезмәт буенча башка чикләүләрне, тыюларны һәм йөкләмәләрне үтәмәүгә;<br>7.2. Татарстан Республикасы дәүләт гражданн хезмәте вазыйфаларын биләүче затлар саны, шул исәптән түбәндәгеләргә бәйле рәвештә:<br>7.2.1. керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар тапшыруга;<br>7.2.2. мәнфәгатьләр низагларын җайга салмауга;<br>7.2.3. Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлары һәм кертемнәре булуга, чит ил финанс инструментларына ия булуга һәм (яки) алардан файдалануга;<br>7.2.4. коррупциячел хокук бозуларга һәвәсләнү турында хәбәрсез булуга;<br>7.2.5. эшмәкәрлек эшчәнлегендә, хуҗалык итүче субъект белән идарә итүдә катнашуга;<br>7.2.6. үзенә буйсынган зат белән якын туганнар булуга;<br>7.2.7. хезмәт вазыйфаларын башкаруга бәйле бүләкләр һәм башка түләүләр алуга;<br>7.2.8. хезмәт буенча башка чикләүләрне, тыюларны һәм йөкләмәләрне үтәмәүгә;<br>7.3. Татарстан Республикасында муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар саны, шул исәптән түбәндәгеләргә бәйле рәвештә:<br>7.3.1. керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар тапшыруга;<br>7.3.2. мәнфәгатьләр низагларын җайга салмауга; | |

| | |
|---|---|
| 7.3.3. Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлары һәм кертемнәре булуга, чит ил финанс инструментларына ия булуга һәм (яки) алардан файдалануга;<br>7.3.4. коррупциячел хокук бозуларга һәвәсләнү турында хәбәрсез булуга;<br>7.3.5. эшмәкәрлек эшчәнлегендә, хуҗалык итүче субъект белән идарә итүдә катнашуга;<br>7.3.6. үзенә буйсынган зат белән якын туганнар булуга;<br>7.3.7. хезмәт вазыйфаларын башкаруга бәйле бүләкләр һәм башка түләүләр алуга;<br>7.3.8. хезмәт буенча башка чикләүләрне, тыюларны һәм йөкләмәләрне үтәмәүгә;<br>7.4. Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затлар саны, шул исәптән түбәндәгеләргә бәйле рәвештә:<br>7.4.1. керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар тапшыруга;<br>7.4.2. мәнфәгатьләр низагларын җайга салмауга;<br>7.4.3. Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлары һәм кертемнәре булуга, чит ил финанс инструментларына ия булуга һәм (яки) алардан файдалануга;<br>7.4.4. коррупциячел хокук бозуларга һәвәсләнү турында хәбәрсез булуга;<br>7.4.5. эшмәкәрлек эшчәнлегендә, хуҗалык итүче субъект белән идарә итүдә катнашуга;<br>7.4.6. үзенә буйсынган зат белән якын туганнар булуга;<br>7.4.7. хезмәт вазыйфаларын башкаруга бәйле бүләкләр һәм башка түләүләр алуга;<br>7.4.8. хезмәт буенча башка чикләүләрне, тыюларны һәм йөкләмәләрне үтәмәүгә.<br>8. Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының (җирле үзидарә органнарының) коррупциоген факторлар ачыкланган норматив хокукый актлары саны.<br>9. Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының (Татарстан Республика- | |

| | |
|---|---|
| сы җирле үзидарә органнарының) коррупциоген факторлар ачыкланган норматив хокукый актлары проектлары саны | |
| 1. Түбәндәгеләрне тикшерүдә тоту буенча үткәрелгән чаралар саны:<br>Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары тарафыннан бюджет законнары үтәлешен (финанс-хуҗалык эшчәнлеген тикшерү);<br>заказчылар тарафыннан дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр башкару, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турындагы законнар үтәлешен;<br>дәүләт заказчылары, заказчы-төзүчеләр тарафыннан төзелеш, реконструкция, капиталь һәм агымдагы ремонт объектларында бюджет акчасын максатчан һәм нәтиҗәле файдалану үтәлешен;<br>Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасының җирле үзидарә органнары тарафыннан җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә законнар үтәлешен.<br>2. Түбәндәгеләрне тикшерүдә тоту буенча үткәрелгән чаралар нәтиҗәләре буенча ачыкланган хокук бозулар саны:<br>Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары тарафыннан бюджет законнары үтәлешен (финанс-хуҗалык эшчәнлеген тикшерү);<br>заказчылар тарафыннан дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр башкару, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турындагы законнар үтәлешен;<br>дәүләт заказчылары, заказчы-төзүчеләр тарафыннан төзелеш, реконструкция, капиталь һәм агымдагы ремонт объектларында бюджет акчасын максатчан һәм нәтиҗәле файдалану үтәлешен; | Татарстан Республикасы Хисап палатасы |

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасының җирле үзидарә органнары тарафыннан җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә законнар үтәлешен.<br>3. Түбәндәгеләрне тикшерүдә тоту буенча үткәрелгән чаралар нәтиҗәләре буенча ачыкланган хокук бозуларның суммада чагылышы:<br>Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары тарафыннан бюджет законнары үтәлешен (финанс-хуҗалык эшчәнлеген тикшерү);<br>заказчылар тарафыннан дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр башкару, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турындагы законнар үтәлешен;<br>дәүләт заказчылары, заказчы-төзүчеләр тарафыннан төзелеш, реконструкция, капиталь һәм агымдагы ремонт объектларында бюджет акчасын максатчан һәм нәтиҗәле файдалану үтәлешен;<br>Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасының җирле үзидарә органнары тарафыннан җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә законнар үтәлешен.<br>4. Түбәндәгеләрне тикшерүдә тоту чаралары йомгаклары буенча кузгатылган административ эшләр саны:<br>Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары тарафыннан бюджет законнары үтәлешен (финанс-хуҗалык эшчәнлеген тикшерү);<br>заказчылар тарафыннан дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр башкару, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турындагы законнар үтәлешен;<br>дәүләт заказчылары, заказчы-төзүчеләр та- | |

| | |
|---|---|
| рафыннан төзелеш, реконструкция, капиталь һәм агымдагы ремонт объектларында бюджет акчасын максатчан һәм нәтиҗәле файдалану үтәлешен;<br>Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасының җирле үзидарә органнары тарафыннан җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә законнар үтәлешен. | |
| 1. Коррупциячел юнәлештәге җинаятьләр буенча каралган эшләр саны.<br>2. коррупциячел юнәлештәге җинаятьләр кылган өчен хөкем ителгән һәм суд тарафыннан законлы көченә кергән гаепләү карарлары чыгарылган затлар саны.<br>3. Коррупциячел юнәлештәге җинаятьләр кылган өчен хөкем ителгән һәм суд тарафыннан законлы көченә кергән гаепләү карарлары чыгарылган дәүләт (муниципаль) хезмәткәрләре саны<br>4. Коррупциячел юнәлештә булган һәм суд тарафыннан законлы көченә кергән гаепләү карарлары чыгарылган җинаятьләр буенча салынган зыян күләме (РФ Җинаять Кодексының 285 – 293 статьялары буенча), мең сум | Суд департаментының Татарстан Республикасындагы идарәсе |
| 1. Хисап чорында хокук саклау органнарына кергән мөлкәтне, җир кишәрлекләрен һәм милек хокукларын дустанә мөнәсәбәттә алу фактлары турында хәбәрләр саны.<br>2. Фактлар мәгълүматлары буенча кузгатылган җинаять эшләре саны, шулардан:<br>2.1. судка җибәрелгән җинаять эшләре саны;<br>2.2. Җинаять эшләре мәгълүматлары буенча чыгарылган гаепләү карарлары саны.<br>3. Аеруча киң җәмәгать резонанслары булган һәм массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртылган рейдерлык фактлары буенча җинаять эшләренең гомуми саны.<br>4. Коррупциячел юнәлештәге җинаятьләр буенча кузгатылган эшләр саны, шул исәптән:<br>4.1. вазыйфаи җинаятьләр (Россия Федерациясе Җинаять кодексының 285 – | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы |

| | |
|---|---|
| 293 статьялары) буенча.<br>5. Коррупциячел җинаятьләр кылган затлар җинаять җаваплылыгына тартылган, шул исәптән:<br>5.1. гражданнар;<br>5.2. вазыйфаи затлар, шуларның:<br>5.2.1. Россия Федерациясе Җинаять кодексының 285 – 293 статьясы буенча, шул исәптән:<br>5.2.1.1. түбәндәге башкарма органнарда вазыйфа биләүче затлар:<br>5.2.1.1.1. Россия Федерациясе дәүләт хакимияте;<br>5.2.1.1.2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте;<br>5.2.1.1.3. Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарында;<br>5.2.1.2. түбәндәге закон чыгару органнарында вазыйфа биләүче затлар:<br>5.2.1.2.1. Россия Федерациясе дәүләт хакимияте;<br>5.2.1.2.2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте;<br>5.2.1.2.3. Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарында;<br>5.2.1.3. коммерциячел яки башка оешмаларда вазыйфа биләүче затлар.<br>6. Россия Федерациясе Җинаять кодексының 285 – 293 статьялары буенча коррупциячел юнәлештәге тикшерелгән җинаятьләр саны | |